ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 гыйнвар 2026 ел № 468

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру максатында, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары белән расланган Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын (алга таба — муниципаль программа) кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программаны тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» 0409 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 1 547 321,16 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2026 ел – 515 773,72 мең сум, 2027 ел – 515 773,72 мең сум, 2028 ел – 515 773,72 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 22 гыйнварындагы
468 номерлы карарына
кушымта

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасы

1 бүлек. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» (алга таба – программа) |
| Муниципаль программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | 1. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>3. «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>4. «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 елның 6 декабрендәге ПУ-1115 номерлы Указы;<br>6. Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы |
| Муниципаль программаны эшләүче | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Муниципаль программаны башкаручылар | 1) Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе;<br>2) Башкарма комитетның мәгариф идарәсе;<br>3) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе (килешү буенча);<br>4) Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе;<br>5) Башкарма комитетның финанс идарәсе;<br>6) архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе |
| Муниципаль программаның максатлары | 1) юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар, шул исәптән балалар санын 17,5 процентка киметү; |

<table>
<tr><td></td><td colspan="4">2) җәмәгать пассажир транспорты катнашындагы юл-транспорт һәлакәтен 25 процентка киметү;<br>3) урам-юл челтәренең (алга таба – УЮЧ) норматив техник торышын ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту.</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаның бурычлары</td><td colspan="4">1) юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;<br>2) машина йөртү культурасын арттыру;<br>3) юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү.<br>4) УЮЧ норматив техник торышын саклап тоту</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="4">Муниципаль программа 2026, 2027, 2028 елларга исәпләнгән</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Еллар буенча бүлеп, муниципаль программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="3">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>515 773,72 мең сум</td><td>515 773,72 мең сум</td><td>515 773,72 мең сум</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="4">Узган елның аналогик чоры (алга таба – УЕАЧ) белән чагыштырганда, 2026-2028 еллар чорына юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булган затлар санын 25 процентка, зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәте санын 10 процентка кимету</td></tr>
<tr><td>Муниципаль программаны тормышка ашыруга контроль</td><td colspan="4">Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Хәл итү өчен муниципаль программа юнәлдерелгән проблемаларны күрсәтеп, аңлатма язуы

2025 елның 10 аенда хезмәт күрсәтелә торган территориядә зыян күрүчеләр булган 400 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 12 кеше һәлак булган һәм 486 кеше төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. УЕАЧ белән чагыштырганда һәлакәтләр саны 2,9% ка (УЕАЧ 412; -12 юл-транспорт һәлакәте) һәм җәрәхәтләнүчеләр 1,2% кимегән (УЕАЧ 492; -6 кеше). Шул ук вакытта һәлак булучылар саны 33,3% ка арту күзәтелә (УЕАЧ 8; +4 һәлак булучылар).

Шәһәрдә «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» (КСАЮ) милли проектында каралган исәп-хисап максатчан күрсәткече үтәлгән, фаразланган күрсәткече 12 булса, 12 кеше һәлак булган.

Килеп чыгу сәбәпләре буенча, зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләренең сан бүленеше һәм әлеге статьялар буенча шәхси состав эше:

- маневрлар ясау кагыйдәләрен бозу (ТС урнашуы, хәрәкәтен үзгәртү, ян як интервалы, дистанция, артка таба хәрәкәт) аркасында 106 юл-транспорт һәлакәте яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 26,5% ы булган (УЕАЧ 97 юл-транспорт һәлакәте; -9,3%), аларда 4 кеше һәлак булган (УЕАЧ 1) һәм 142 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 124 кеше).

Шәхси состав тарафыннан маневрлар ясау кагыйдәләрен бозуның 3249 очрагына чик куелган (УЕАЧ 4315; -24,7%), бу машина йөртүчеләр тарафыннан ачыкланган юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 11,4% тәшкил итә.

- юл чатында йөрү кагыйдәләрен бозу (юлда йөрү чираты, әйләнмәле хәрәкәт, светофор) аркасында 53 юл-транспорт һәлакәте яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең

13,3% ы (УЕАЧ 89 юл-транспорт һәлакәте; -40,4%) булган, аларда һәлак булучылар юк (УЕАЧ 2) һәм 79 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 120 кеше).

Шәхси состав тарафыннан юл чатында йөрү кагыйдәләрен бозуның 1993 очрагына чик куелган (УЕАЧ 577; 2,4 тапкыр), бу машина йөртүчеләр тарафыннан ачыкланган юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 7% тәшкил итә.

- билгеләнгән тизлекне арттыру аркасында 48 юл-транспорт һәлакәте яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 12% ы булган (УЕАЧ 26 юл-транспорт һәлакәте; +84,6%), аларда 1 кеше һәлак булган (УЕАЧ 0) һәм 62 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 32 кеше).

- җәяүлеләр кичүен үтү кагыйдәләрен бозу аркасында 70 юл-транспорт һәлакәте яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 17,5% ы булган (УЕАЧ 53 юл-транспорт һәлакәте; +32,1%), аларда 3 кеше һәлак булган (УЕАЧ 1) һәм 68 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 58 кеше).

Шәхси состав тарафыннан җәяүлеләр кичүен үтү кагыйдәләрен бозуның 544 очрагына чик куелган (УЕАЧ 327; +66,4%), бу машина йөртүчеләр тарафыннан ачыкланган юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 1,9% тәшкил итә.

- җәяүлеләр тарафыннан юл йөрү кагыйдәләрен бозу аркасында 45 юл-транспорт һәлакәте яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 11,3%ы булган (УЕАЧ 49 юл-транспорт һәлакәте; -8,2%), аларда 1 кеше һәлак булган (УЕАЧ 3) һәм 44 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 47 кеше).

Шәхси состав тарафыннан җәяүлеләрнең юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 577 очрагына (УЕАЧ 600; -3,8%) яки барлык юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 2,0% чик куелган.

Исерек хәлдә булган җәяүлеләр гаебе белән юл-транспорт һәлакәте теркәлмәгән (УЕАЧ 1 юл-транспорт һәлакәте).

Юл хәрәкәтендә катнашучылар имгәнгән аварияләрнең төп төрләре булып түбәндәгеләр тора:

- автомобильләр бәрелешү, 153 юл-транспорт һәлакәте булган, бу юл-транспорт һәлакәтләренең гомуми санының 38,2% тәшкил итә (УЕАЧ 183 юл-транспорт һәлакәте; -16,3%), аларда 4 кеше һәлак булган (УЕАЧ 3) һәм 220 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 252 кеше);

- җәяүлеләрне бәрдерү, 132 юл-транспорт һәлакәте булган, бу юл-транспорт һәлакәтләренең гомуми санының 33,0% тәшкил итә (УЕАЧ 125 юл-транспорт һәлакәте; +5,6%), аларда 5 кеше һәлак булган (УЕАЧ 3) һәм 128 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 129 кеше).

Җәяүлеләр кичүләрендә җәяүлеләрне бәрдерүнең 70 очрагы булган (УЕАЧ 52; +34,6%), аларда 3 кеше һәлак булган (УЕАЧ 0) һәм 68 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 58).

- каршылыкка бәрелү, 40 юл-транспорт һәлакәте булган, бу юл-транспорт һәлакәтләренең гомуми санының 10% тәшкил итә (УЕАЧ 24 юл-транспорт һәлакәте, -33,4%), аларда 2 кеше һәлак булган (УЕАЧ 0) һәм 56 кеше җәрәхәтләнгән (УЕАЧ 29 кеше).

Юл-транспорт һәлакәтләрен атна көннәре буенча бүлү. Иң аварияле көне:

- пәнҗешәмбе - 62 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, бу көнгә барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 15,5% ы туры килә, аларда 3 кеше һәлак булган һәм 65 кеше җәрәхәтләнгән.

- җомга - 61 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, бу көнгә барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 15,3% ы туры килә, аларда 1 кеше һәлак булган һәм 76 кеше җәрәхәтләнгән.

Юл-транспорт һәлакәтләренең тәүлек вакыты буенча бүленешен анализлау, бүгенге көндә түбәндәгеләрнең иң аварияле вакыт булуын күрсәтә:

- 15 сәгатьтән 18 сәгатькә кадәр - әлеге вакыт аралыгында 85 юл-транспорт һәлакәте яки барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 21,2% ы булган, аларда 1 кеше һәлак

булган һәм 92 кеше җәрәхәтләнгән.

- 12 сәгатьтән 15 сәгатькә кадәр - әлеге вакыт аралыгында 78 юл-транспорт һәлакәте булган, ягъни барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 19,5% ы булган, аларда 1 кеше һәлак булган һәм 92 кеше җәрәхәтләнгән.

Балаларның юл-транспорт травматизмы

2025 елның 10 аенда Яр Чаллы шәһәре юлларында 16 яшькә кадәрге балалар катнашында 82 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда һәлак булучылар юк һәм 85 балигъ булмаган бала төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган. Узган елның аналогик чорында 74 юл-транспорт һәлакәте булган, аларда 1 бала һәлак булган һәм 80 балигъ булмаган бала зыян күргән. Юл-транспорт һәлакәтләре саны 10,8% ка һәм аларда зыян күргән балалар саны 6,25% ка арткан.

Хисап чорында пропаганда бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында юл-транспорт травматизмын профилактикалау буенча 139 тематик чара уздырылган (УЕАЧ 146). Бүлек офицерлары 20 ата-аналар җыелышында (УЕАЧ 20) һәм мәгариф хезмәткәрләре белән 11 киңәшмәдә (УЕАЧ 18) катнаштылар. Мәгариф идарәсе белән берлектә 27 шәһәр конкурсы (УЕАЧ 29) һәм юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча 21 акция (УЕАЧ 32) оештырылган. ЮХИДИ бүлеге һәм юл-патруль хезмәте аерым ротасы хезмәткәрләре белән берлектә мәктәпләрдә, балалар бакчаларында һәм техникумнарда юл-транспорт травматизмын профилактикалау буенча 639 лекция үткәрелгән (УЕАЧ 757).

Бүлекчә эшчәнлегенең төп юнәлеше булып массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек тора. Пропаганда бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан түбәндәгеләр әзерләнде:

- телевидениедә 1364 сюжет (УЕАЧ 1190);
- радиода 414 материал (УЕАЧ 642);
- 1652 мәкалә матбугат басмаларында һәм мәгълүмат агентлыкларының интернет порталларында бастырып чыгарылды (УЕАЧ 1521).

## 3 бүлек. Программа чаралары.

## Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау.

| Максат | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чаоралары үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау һәм финанслау чыганаклары | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2025 база | 2026 | 2027 | 2028 | 2026 | 2027 | 2028 |
| Юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булучылар, шул исәптән балалар санын кимету | Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы ясау системасы булдыру | «Яшь Хәрәкәт Инспекторы» кысаларында гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары белән «Куркынычсыз тәгәрмәч» конкурсы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | Ел саен | Катнашкан укучылар саны | 290 | 290 | 290 | 290 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен «Игътибар - балалар!», «Игътибар - җәяүле!», акцияләре | | Ел саен | Гомуми белем бирү учреждениеләре нең гомуми санында катнашкан укучылар өлеше, % | 95 | 95 | 95 | 95 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны куркынычсыз юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтү буенча «Куркынычсыз | | Ел саен | Уткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | Чара оештыру характерына ия | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | юл» дидактик уеннар зональ конкурсы | | | | | | | |
| | | Гомуми белем бирү учреждение ләрендә «Юл хәрәкәте иминлеге» темасына лекцияләр | ДАИ (килешү буенча) | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 139 | 139 | 139 | 139 | Чара оештыру характерына ия |
| | | Массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте имин леген тәэмин итү буенча материалларны яктырту | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | Даими | Урнаштырылган материаллар саны, берәмлек | 12 | 12 | 12 | 12 | Чара оештыру характерына ия |
| | | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Юл хәрәкәте иминлеге» темасына ата-аналар җыелышлары үткәрү | | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | Чара оештыру характерына ия |
| Җәмәгать пассажирлар транспорты катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен киметү | Машина йөртү культурасын арттыру | «Хаким Кубогы»на магистраль автопоездлар йөртүчеләрнең һөнәри осталык бөтенроссия конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Татарстанның Логистика ассоциациясе (килешү буенча) | Ел саен | Катнашучылар саны, кеше | 30 | 30 | 30 | 30 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Җәмәгать транспортын йөртүчеләрнең һөнәри осталык шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, «Горкоммунхоз» МУП (килешү буенча) | Ел саен | Катнашучылар саны, кеше | 25 | 25 | 25 | 25 | Чара оештыру характерына ия | | |
| | | Җәмәгать транспорты йөртүчеләр белән стресс тотрыклылыгы һәм клиент ориентлашуы буенча курслар | | Ел саен | Үткәрелгән лекцияләр саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | Чара оештыру характерына ия | | |
| УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту | Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү | Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү (муниципаль программага кушымта) | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Ел саен | Бетерелә торган юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарының саны | 14 | 12 | 10 | 9 | | | |
| | УЮЧнең норматив техник халәтен саклап тоту | Юллар, күперләр һәм тротуарларны карап тоту һәм ремонтлау | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Ел саен | Карап тотуны боззу буенча ДАИ күрсәтмәләренең саны | 100 | 100 | 99 | 95 | Муниципаль бюджет 515773,72 мең сум | Муниөипаль бюджет 515773,72 мең сум | Муниципаль бюджет 515773,72 мең сум |
| | | Юлларны кыш көне карап тоту | | Ел саен | Карап тотуны боззу буенча ЮХИДИ күрсәтмәләренең саны | 30 | 30 | 29 | 28 | | | |
| | | Юл билгеләре урнаштыру | | Ел саен | ЮХИДИ күрсәтмәсе буенча урнаштырылган юл билгеләренең | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | өлеше, % | | | | | | | |
| | | Юл билгеләре ясау | | Ел саен | Юл билгесе булган автомобиль юлларының өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | Светофор объектлары | | Ел саен | ЮХИДИ күрсәтмәсе буенча урнаштырылган светофор объектларының өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| Аз мобильле автотранспорт йөртүчеләр катнашында юл-транспорт һәлакәтен кимету | Юл хәрәкәте өлкәсендәге хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт булдыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру | Питбайклардан файдалануга каршы юнәлдерелгән ачык төстәге слоганлы баннерлар урнаштыру | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | Ел саен | Урнаштырылган материал саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | | | |
| Автотранспорт йөртүчеләр катнашында юл-транспорт һәлакәтен кимету | Юл хәрәкәте өлкәсендәге хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт булдыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру | Машина йөртүчеләр тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуга каршы юнәлдерелгән ачык төстәге слоганлы баннерлар урнаштыру | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | Ел саен | Урнаштырылган материал саны, берәмлек | 3 | 3 | 3 | 3 | | | |

## 4 бүлек. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итү

Муниципаль программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 547 321,16 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларын файдалану күздә тотыла: 2026 ел – 515 773,72 мең сум, 2027 ел – 638 430,4 мең сум, 2028 ел – 515 773,72 мең сум.

## 5 бүлек. Муниципаль программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү

Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе үз компетенциясе чикләрендә программа чараларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

Муниципаль программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗәлелек түбәндәгеләр хисабына ирешелә:

1) юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булучылар санын киметү;

2) җәмәгать пассажир транспорты катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен киметү;

3) УЮЧ норматив техник торышын саклау.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Муниципаль программага
кушымта

Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү

| № т/б | Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе адресы | Аварияләрне киметү буенча тәкъдим ителә торган чаралар Счастливый 17-23-7443 ИДН 17-07 17-18 ЗЯБ поселогы | Муниципаль программаны финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|
| 1. | М. Җәлил проспекты – Батенчук урамы | 1. Барлык юнәлешләрдә дә светофорның кызыл сигналына биш секундлык тоткарлык кертү.<br>2. М. Җәлил проспекты буенча тавыш полосалары ясау.<br>3. Батенчук урамы буенча Ямашев урамы ягында:<br>1) тавыш полосалары ясау;<br>2) җайга салынмый торган җәяүлеләр кичүе каршында «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>3) «Ясалма тигезсезлек» 1.17 юл билгесе урнаштыру – 1 данә<br>4. М. Җәлил проспекты буенча Гидростроители урамы ягында «Максималь тизлекне 40 км/сәг чикләү» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 2 данә. | Җирле бюджет |
| 2. | Яшьлек проспекты – 40 лет Победы урамы | Барлык юнәлешләрдә дә светофорның кызыл сигналына биш секундлык тоткарлык кертү. | Җирле бюджет |
| 3. | Чулман проспекты – Х. Туфан проспекты | 1. Барлык юнәлешләрдә дә светофорның кызыл сигналына биш секундлык тоткарлык кертү.<br>2. Х. Туфан проспекты буенча:<br>1) тавыш полосалары ясау;<br>2) «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 4 данә;<br>3) ике юнәлештә дә «Тигезсез юл» 1.16 юл билгесе урнаштыру – 2 данә. | Җирле бюджет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 3. Чулман проспекты буенча 13 комплекс ягында «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 һәм «Тигезсез юл» 1.16 юл билгеләрен күчерү (тавыш полосалары алдыннан урнаштыру) | |
| 4. | Минзәлә тракты, 1<br>(Орловка боҗрасы) | Барлык юнәлешләрдә дә светофорның кызыл сигналына биш секундлык тоткарлык кертү | Җирле бюджет |
| 5. | Татарстан урамы –<br>Ш. Усманов урамы | 1. Татарстан урамы буенча:<br>1) тавыш полосалары ясау;<br>2) «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 4 данә (үлчәме 70);<br>3) ике юнәлештә дә «Тигезсез юл» 1.16 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>4) юл чатында юл билгесе ясау | Җирле бюджет |
| 6. | Машиностроительная урамы – Вахитов проспекты<br>(Вахитов боҗрасы) | 1. Боҗралы юл чатында хәрәкәт юнәлешен күрсәтүче 1.1 һәм 1.18 юл билгеләре ясау (термопластик белән).<br>2. «Полосалар буенча хәрәкәт юнәлеше» 5.15.1 юл билгесе урнаштыру – 2 данә. | Җирле бюджет |
| 7. | Машиностроительная урамы, 75 («Мегастрой» СҮ) | Светофорга кадәр тавыш полосалары ясау | Җирле бюджет |
| 8. | Машиностроительная урамы, 96, 1 төзелмә<br>( «Бархан» базары) | Хәрәкәт юнәлешен күрсәтүче 1.1 һәм 1.18 юл билгеләре ясау (термопластик белән) | Җирле бюджет |
| 9. | М. Җәлил проспекты –<br>«Центральная» а/т | Тавыш полосалары ясау | Җирле бюджет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Яр Чаллы проспекты – «Челныгорстрой» а/т | 1. Яр Чаллы проспекты:<br>1) тавыш полосалары ясау;<br>2) «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 4 данә;<br>3) ике юнәлештә дә «Тигезсез юл» 1.16 юл билгесе урнаштыру – 2 данә. | Җирле бюджет |
| 11. | КАМАЗ-Мастер урамы, 11 | Һәр җәяүлеләр кичүе алдыннан «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 6 данә. | Җирле бюджет |
| 12. | М. Җәлил проспекты, 53 – «Камснаб» | 1. М. Җәлил проспекты буенча 9 комплекс ягында җирле юл:<br>1) «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 1 данә;<br>2) «Ясалма тигезсезлек» 1.17 юл билгесе урнаштыру – 1 данә;<br>3) «Ясалма тигезсезлек» 5.20 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>4) «Балалар» 1.23 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>5) «Гамәлдә булу зонасы» 8.2.1 юл билгесе урнаштыру;<br>6) «Максималь тизлекне чикләү зонасы тәмамлану» 3.25 юл билгесе урнаштыру – 1 данә;<br>7) җәяүлеләр кичүе алдыннан ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру – 1 данә.<br>2. М. Җәлил проспекты буенча 10 комплекс ягында җирле юл:<br>1) «Максималь тизлекне чикләү 40 км/сәг» 3.24 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>2) «Ясалма тигезсезлек» 1.17 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>3) «Ясалма тигезсезлек» 5.20 юл билгесе урнаштыру – 4 данә;<br>4) «Балалар» 1.23 юл билгесе урнаштыру – 4 данә;<br>5) «Гамәлдә булу зонасы» 8.2.1 юл билгесе урнаштыру – 1 данә;<br>6) «Максималь тизлекне чикләү зонасы тәмамлану» 3.25 юл билгесе урнаштыру – 2 данә;<br>7) җәяүлеләр кичүе алдыннан ясалма юл тигезсезлеге урнаштыру – 1 данә. | Җирле бюджет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | Хәсән Туфан проспекты, 22/9 йорт | Борылманы ябу | Җирле бюжет |
| 14. | Машиностроительная урамы, 29 | Өч юлның берсе - Леруа Мерленнан чыгу (борылышка таба турыдан-туры юл чатына чыгу) юлы юкка чыгарылган. | Җирле бюжет |